ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.11.2021 ел Баулы шәһәре №205

Татарстан Республикасы Баулы
муниципаль районында «Балаларны
мәктәпкәчә белем бирүнең төп
белем бирү программасын гамәлгә
ашыручы мәгариф оешмаларына
(балалар бакчаларына) кабул итүгә
гаризалар кабул итү, күчерү
һәм исәпкә кую» муниципаль
хезмәтен күрсәтүнең административ
регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Балаларны мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) кабул итүгә гаризалар кабул итү, күчерү һәм исәпкә алу» муниципаль хезмәтен күрсәтүнең административ регламентының якынча формасын раслау турында» 2021 елның 6 ноябрендәге 1417-21 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Кушымтадагы Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында «Балаларны мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчаларының) төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына кабул итүгә гаризалар кабул итү, күчерү һәм исәпкә кую» муниципаль хезмәтен күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчалары) балаларны исәпкә кую һәм исәпкә алу» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 17 маендагы 141 номерлы карары һәм «Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 17 маендагы 141 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүнең

төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм күчерү» муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2019 елның 27 августындагы 252 номерлы карарлар үз көчләрен югалткан дип танырга.

3. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУны Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына гаризалар кабул итү, балаларны исәпкә кую һәм күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча вәкаләтле орган дип билгеләргә.

4. Баулы муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары җитәкчеләренә әлеге карарны ата-аналар (законлы вәкилләр) танышырлык урыннарда урнаштырырга.

5. Әлеге карарны http://www.pravo.tatarstan.ru адрес буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://www.bavly.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында бастырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров